БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«14» 10 2019 г. № 323

Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитетының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законына (алга таба - 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон), «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында «2014 елның 24 июлендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына нигезләнеп, Татарстан Республикасының Балтач районы башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитетының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының оештыру-гомуми бүлеге җитәкчесенә йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов